УДК 821.512.145-1:75
ББК 84(2Рос=Тат)-5:85.147
С78
*Николай Переяслов* тәрҗемәсе
Рәссамнары: *Фәридә Хәсьянова, Ринат Хәсәншин*
**Суюров Ф.А.**

Пейзаж. Лирика: альбом / Фәрит Суюров, Ренат Харис; кереш сүз авт. Р.Харис. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 108 б. — 1000 д. — ISBN 978-5-298-01720-6

ISBN 978-5-298-01720-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Суюров Ф.А., Харис Р.М., 2008

Фәрит Суюров
Пейзаж лирика
Ренат Харис
Казан Татарстан китап нәшрияты Татарское книжное издательство 2008

# Пейзаж һәм лирика

Әдәбият һәм сынлы сәнгать арасында һәрвакыт бер-берсен баетып торучы бәйләнеш булган, бар һәм булачак та. Әдәбият гасырлар дәвамында рәссамга илһам чыганагы һәм үз әсәрләрен тудыру өчен сәбәп-этәргеч була килгән. Ренессанс чоры сынлы сәнгатенең Библия сюжетларына таянганлыгы һәркемгә билгеле. Әлеге классик традиция бүген дә дәвам итә. Моңа тагын бер ачык мисал — китап иллюстрациясе жанрының бүгенге үсеше. Бу жанрның иң күренекле әсәрләре элек тә, хәзер дә мөстәкыйль әсәр буларак бәяләнгәннәр, алар күргәзмәләрдә катнашалар, музейларда сакланалар.

Ләкин безнең очракта эш башкачарак булып чыкты — шагыйрьгә бу юлы иҗади этәргечне рәссам әсәрләре бирде. Мин Казанның Габдулла Тукай музеенда күренекле пейзаж остасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Фәрит Суюровның күргәзмәсе ачылышында катнаштым. Күргәзмәдә рәссамның пастель буяулары белән язылган егермеләп әсәре куелган иде. Аларның һәрберсе ничектер мине үз янында гадәттәгедән озаграк басып торырга мәҗбүр итте, каядыр ымсындырды, чакырды, тартып кертте. Мин үземне Казма, Кәшә авыллары янындагы Зөя елгасында коенгандай, Бик-Үти кырында Олы Болада балык каптыргандай, Фролово таллыгында, Каенлык яисә Толымбай урманнарында йөргәндәй хис иттем... Мин балачагым дөньясында идем... Пастельнең бәрхетләнеп торган төсләре җанымны назладылар, фантазиямне кытыкладылар, һәм мин, сурәтләрдәге пейзажларның матурлыгына соклванудан да узып, әсәрләрнең үзләрен «укырга» керешкәнемне, алардагы агачлар, чәчәкләр, болытлар, яфраклар, көртләр, кар сулары белән «сөйләшә» үк башлаганымны сизеп алдым... Әмма ул вакытта өлкән кешенең балаларча шатлануы шигырьгә әверелми калды. Бу хис, эреп, җаныма сеңгәндер, бәлки, башка, көнкүрештәге актуальрәк кичерешләр, мәшәкатьләр астында күмелеп калгандыр.

Фәрит Абдрахманович пастельләре белән икенче җитди очрашу рәссамның өендә булды. Ул әсәрләрен фатирының диварларына элеп куйган. Кайбер картиналар миңа электән үк төрле күргәзмәләр аша таныш иде, ә күбесен беренче тапкыр күрүем. Һәм мине Тукай музеенда җаныма сеңгән балачак шатлыгы кабат биләп алды. Әмма бу хис элеккесеннән баерак, аңа дулкынландыргыч, уй-фикерне дөрләтеп җибәрә торган әллә нинди көч өстәлгән. Пастельнең ярым үтә күренмәле төсмерләре аша күз карашым картиналарның эчкәресенә саркып керә, анда рәссамның хис-тойгылары белән очраша да образлы фикергә, ягъни поэзиягә әверелә башлады.

Һәм шунда, мине гаҗәпкә калдырып, Фәрит Абдрахманович икебезгә бер китап чыгару турында тәкъдим ясады: аның пастель белән язган пейзажлары һәм минем шигырьләр! Мин, уйлап та тормастан, шунда ук ризалык бирдем.

Шунысын да әйтим, мондый халәт белән минем очрашуым беренче генә түгел. Кайчандыр күңелемә Огюст Роденның фәлсәфи скульптуралары, Бакый Урманче сыннары, Николай Фешинның искитмәле полотнолары илһам ялкыны биргән иде һәм мин шигырьләр, шигырьләр циклы, поэма язган идем. Мин дөньяның данлыклы байтак музейларында, сәнгать галереяларында булдым, бөтен дөньяга мәгълүм бөек осталарның пейзажларын күрдем, сокландым. Әйе, шаккаттым, әмма шуннан да артыграк түгел. Ә менә Суюровның бер карашка гади генә, галәми данга дәгъва итми торган пейзажлары ни өчендер мине кулыма каләм алырга һәм бер китаплык пейзаж шигырьләре язарга мәҗбүр итте. Ни өчен? Анык җавап таба алмыйм. Шунысы шиксез: алар, димәк, минем өчен алай ук гади булмаганнар!.. Әйе, иҗат психологиясенең серләренә җиде кат йозак салынган һәм аларның ачкычлары бер генә кулда түгел...

Шигырьләремне тәрҗемәгә Мәскәү шагыйре Николай Переясловка җибәрдем. Ул аларны, Суюровның пастельләрен күрмичә, мөстәкыйль шигырьләр буларак тәрҗемә итте. Алар, чыннан да, рәсемнәрнең тасвиры түгел. Рәсемнәр дә шигырьләргә иллюстрация түгел. Һәр икесе дә тулаем мөстәкыйльләр. Әмма алар арасында ниндидер бер бәйләнеш бар: җырда — сүз белән көй арасындагыдай, балетта — музыка белән хәрәкәт арасындагыдай. Шигырь белән музыка кавышса, җыр, романс, кантата дөньяга килә — мин моны яхшы беләм. Ләкин шигырь белән рәсем, сүз белән төс гыйшкыннан ни туасын күз алдына да китерә алмыйм.
Һәм алар бер игелекле көнне кавыштылар — мин шигырьләрне һәм аларның русчага тәр-җемәләрен Фәрит Суюров пастельләре фонында укыдым. Икебез өчен генә. Уку барышында шигырьләрнең дә, рәсемнәрнең дә яңа серләре ачылгандай, күркәмлекләре арткандай булды.
Һәм шунда без, хөрмәтле сәнгать һәм шигырь сөючеләр, Татарстан китап нәшрияты аша үзебезнең уртак эшебезне сезгә тәкъдим итәргә кирәк дигән фикергә килдек.

**Ренат Харис**,
Татарстан Республикасының
халык шагыйре

# Пейзаж и лирика

Между литературой и изобразительным искусством всегда была, есть и будет плодотворная взаимообогащающая связь. Литературное произведение часто становилось для художника поводом-толчком для создания своих произведений. Общеизвестно, что почти всё изобразительное искусство эпохи Возрождения так или иначе опирается на библейские сюжеты. Эта классическая традиция имеет продолжение и в наше время. Другим ярчайшим примером является жанр книжной иллюстрации. Выдающиеся достижения этого жанра затем становились и становятся самостоятельными произведениями и начинают жить своей выставочной и музейной жизнью.
В нашем случае всё было наоборот — картины художника дали толчок творческому вдохновению поэта. И это случилось на персональной выставке известного пейзажиста, заслуженного деятеля искусств Республики Татарстан Фарита Суюрова, организованной в залах музея Габдуллы Тукая. Каждая картина меня останавливала возле себя, долго не отпускала, куда-то манила-приглашала. Я не обращал внимания на их названия. Я уже купался в Свияге возле деревень Казма или Кэшэ, ловил рыбу в речке Большая Була около деревни Бик-Утеево, ходил по Фроловскому тальнику, бродил по Каенлыкскому или Тулумбайскому лесу Буинского района... Я попал в мир своего детства... Бархатистые цвета пастели ласкали мою душу, щекотали мою фантазию, и я почувствовал, что не только умиляюсь, удивляюсь красоте изображённой природы, но и «читаю» картины художника, «разговариваю» с деревьями, цветами, облаками, листьями, снегом, талой водой... Однако в то время эта детская радость взрослого человека не превратилась в стихи. Она как-то незаметно растворилась в душе, была оттеснена другими, возможно, более актуальными чувствами, переживаниями и заботами.
Вторая серьёзная встреча с пастелями Фарита Абдрахмановича состоялась у него дома. Невысокие стены его квартиры были обвешаны многочисленными картинами. Некоторые из них мне были уже знакомы по выставкам, а некоторые впервые предстали перед моими глазами. И я вновь почувствовал в душе ту детскую радость, которую ощутил при первой встрече с ними в музее Тукая. Но к этой радости добавилось ещё что-то волнующее, взбудораживающее мысль. Через полупрозрачность пастельных тонов взор мой уходил в глубь картин, соприкасался там с чувствами художника и превращался в образную мысль, то есть — в поэзию.
И каково же было моё удивление, когда Фарит Абдрахманович предложил мне подумать о совместном издании его пастелей и моих стихов! Я тотчас согласился.
Справедливости ради должен сказать, что с подобным творческим всполохом души я встречаюсь не впервые. Когда-то на меня вдохновляюще воздействовали философские скульптуры Огюста Родена, изваяния Баки Урманче, ошеломляющие картины Николая Фешина, и я написал стихи, цикл стихотворений и поэму. Я побывал во многих знаменитых музеях и картинных галереях мира, любовался, восхищался пейзажами всемирно известных великих мастеров живописи. Восторгался до слёз, но не более. А вот, казалось бы, простенькие, надо прямо сказать — не претендующие на всемирную известность, пейзажи Фарита Суюрова чем-то заставили меня взяться за перо и написать целую книгу пейзажных стихов. Чем же? Однозначного ответа нет. Одно могу сказать: для меня они оказались вовсе не простенькими!.. Да, тайны психологии творчества за семью замками и ключи от них не в одних руках...
Стихи я послал замечательному московскому поэту Николаю Переяслову, который перевёл их как самостоятельные произведения, то есть не видя картин художника. Да, они — не описания картин и имеют свою собственную полнокровную жизнь точно так же, как картины не являются иллюстрациями к моим

стихам. Но между ними установилась какая-то связь: как между словами и мелодией в песне, как между музыкой и движением в балете. Я хорошо знаю: когда стихи обнимаются с музыкой, рождается песня, романс, кантата. Но я не знаю что возникает, когда влюбляются друг в друга стихи и картины, слова и цвет.
И в один прекрасный день картины и стихи встретились — я читал стихи и их переводы на русский язык на фоне картин Фарита Абдрахмановича Суюрова. Читал не для публики, читал только для нас — соавторов. И мы оба почувствовали, что в процессе чтения приоткрываются новые таинства и стихотворений, и картин, они приобретают новые, весьма привлекательные качества.
Тогда мы решили попросить Татарское книжное издательство донести наше сотворчество до вас, дорогие любители живописи и поэзии.

**Ренат Харис**,
народный поэт
Республики Татарстан

* * *
Болытларны җилләр куа.
Җилләрне кемнәр куа?
Болытлы елгага карап,
дулкынлы сорау туа.

Уйлар айкый күк гөмбәзен,
айкый сулар чоңгылын.
Әкияти хисләр күңелгә
урнашалар чын булып.

Әллә судан, әллә күктән
иңә кодрәт тавышы:
«Бар нәрсәне алга куа
бөек Вакыт агышы!..»

* * *
Гонит ветер в небе облака,
треплет ивам лиственные косы.
«Кто его к нам гнал издалека?» —
сам себе я задаю вопросы.

Мчат они орлами в небеса,
словно птиц, гоня ответов стаю.
И в душе, как дивные леса,
неземные чувства вырастают.

И услышит сердце, а не слух,
как придёт ответ из тьмы безгласной:
«У всего на свете есть Пастух.
Это — Время. Всё ему подвластно...»

* * *
Актарылып төшкән тамыр
су буйлап агып бара...
Нәрсә тамыры икән ул? —
чәнчелебрәк кара!

Кәүсәсез калган тамыр ул —
кешесез калган исем.
Миңа шундый бер уй килде.
Ә син аны ни дисең?

Ә елга да гади түгел —
Тарихтыр әле, баксаң...
Нишләр икән безнең исем,
вакыт дулкыны какса?..

* * *
Смотрю на реку. А по глади вод —
древесный корень медленно плывёт...
Кого питал он, когда рос в земле?
Какие соки пил в глубинной мгле?

Плывёт, качаясь, словно мёртвый зверь,
как будто имя, что ничьё теперь:
тверди его хоть про себя, хоть вслух —
оно мертво, коль с ним расстался дух...

Смотрю на реку: то и впрямь — река?
Иль то плывут меж берегов — века?
Ужель вот так и наши имена,
как этот корень, унесёт волна?..

* * *
Елга аңламый урманны —
ник шаулый да ник сайрый,
ник маңгай сырына охшаш
җыерчык баскан кайры?!

Урман аңламый елганы —
үз ярларын ник ашый,
ник бетми өзлексез суы,
ул аны кемгә ташый?

Ике бөек сер иясе
тора минем алдымда...
Алар миндә... Мин аларны
аңламыйм да, аңлыйм да...

* * *
Река течёт себе, не зная,
из-за чего окрестный лес
порой шумит, себя терзая,
словно в него вселился бес.

И лес стоит, не понимая
жизнь рек, что точат берега —
куда по ним к началу мая
уходят талые снега?

И сам я тоже, тоже, тоже
постичь не в силах — ничего.
Смотрю на мир — и сердце гложет
непониманье тайн его...

* * *
Күзләргә алып керәләр
сукмаклар безне кинәт,
гәрчә күңелнең мәңгелек

җәйдә каласы килә...

Үләннәр суты суынган,
гөлләрдә хуш ис беткән...
Шушымы, «Бәхет алда!» дип,
без зарыгыплар көткән?!

Шулар бәрабәренә көз,
күз буяр өчен генә,
алтын диеп бүләк итә
алтынның төсен генә...

* * *
Душа ещё живёт теплом
и задержаться лето просит,
а где-то рядом, за углом,
уж дышит изморозью осень.

И замедляет кровь свой бег,
почуяв леденящий холод.
И для чего теперь успех
и славы звон, коль ты — не молод?

А осень вновь, дурача нас
иль продолжая мстить за что-то,
словно прораб в расчётный час,
кладёт к ногам — в который раз! —
не золотых монет запас,
а только листьев позолоту...

* * *
Тынчу суларда — тынычлык.
Ләкин бу тынычлыкта
суның иң гүзәл сыйфаты
ята ваемсыз йоклап —

алга таба ашкынуы!
Ә бу теләк оюга,
суга чәчәк кебек матур,
тик хәтәр афәт йога.

Су әверелә баткакка —
хәшәрәт оясына,
дулкынлана белүләрен
оныткан күңел сыман...

* * *
Вода стоячая — зеркальна
и неподвижна с давних пор,
её частицы не сверкали,
свергаясь вниз с высоких гор.

В ней нет желанья мчаться к устью,
спеша безудержно вперёд.
И, наполняя душу грустью,
над ней — дух гнилости плывёт.

Она давно болотом стала,
в котором жизни гул затих,
словно душа, что перестала
страдать и плакать за других...

* * *
Эңгер әле килә генә,
ә җил тынып өлгергән...
Һава да, су да шәмәхә
тылсым имә эңгердән.

Су куера, әйтерсең лә
гипнозлы күз карасы.
Шомлы суга тартыласың,
килмәсә дә барасы.

Куркуны җиңеп керәсең
камышлар арасына,
тәвәккәллисең — чумасың
Галәм күз карасына.

* * *
Легла на землю мгла тенистая,
ни лист не дрогнет, ни трава.
Вода и воздух пьют неистово
коктейль ночного колдовства.

Вода влечёт к себе магически,
словно она — гипнотизёр,
и ты тревожишься панически,
но отвести не можешь взор.

Борясь со страхом, ты решаешься
и, дождь волос собрав в пучок,
идёшь к воде — и погружаешься
в горящий Космоса зрачок.

* * *
Елга таллар арасына
поскан җирдә, иркенләп,
кызлар су керә. Ә безнең
күзләр шунда береккән.

Беренче тапкыр кызларны
шулай күреп соклану!..
Беренче тапкыр хисләргә
кан тула дулкынланып...

Күзне уч белән каплыйсың...
Ләкин учлар пыяла...
Булган икән тиле чаклар —
хәтта күзләр оялган!..

* * *
Там, где речка свои воды
от чужих скрывала глаз,
обезумев от свободы,

мылись девки в ранний час.

Без купальников, нагие,
веселились стайкой фей...
И на их тела тугие
я глядел из-за ветвей.

Ни ресницы, ни деревья
не скрывали сладкий вид...
...Было, было, было время,
когда очи знали стыд!

* * *
Көз — агачларның җитлеккән,
Сократ күк тирән чагы.
Ябалдашта — кара уйлар,
тамырда — уйның агы.

Һәм кәүсәдә тоташалар
өмет һәм өметсезлек...
Икесе дә бер үк төштә
яшәү дәвамы эзли.

Карлы уйга чума агач,
кыш буе уйда яши...
Язга чыккач, сүзен әйтә —
сүз, өмет кебек, яшел.

* * *
Осень — время зрелости. В лесу —
все деревья кажутся Сократами.
Кроны — груз уныния несут,
а в корнях — живут мечты стократные.

На пути до кроны от корней —
безысходность и надежда сходятся,
и в теченье долгих зимних дней,
как в ларце, в стволе они находятся.

Белый снег уронит скоро высь,
и весь мир предстанет чистым, новым!..
А весною лес изронит мысль,
нам её шепча зелёным словом.

* * *
Гүзәл йөзгә дә кайвакыт
тылсымлы миң сер өсти.
Миң шикелле түгәрәк күл
ямьле итә җир өстен.

Суына карап торасың —
агач, гөлләр чагылган.
Зәңгәр казанында кайнап,
ап-ак таулар агыла.

Суга керсәң, шул тауларның
тотарсың кебек карын...

Судагы сурәт уята
балачак хыялларын...

* * *

Родинка над верхнею губой —
личика любимого отличье.
Озеро с водою голубой —
украшает Родины обличье.

Средь небес, от марева слепых,
тень орла вершит своё круженье,
и кипят в глубинах голубых
белых гор окрестных отраженья.

Так и мнится, что ступи на дно —
и рукой потрогаешь вершины.
Что за чудо — озеро! Оно
духом детства полнит грудь мужчины.

**Аюдаг**

Бер шук малай су эчкән дә
юлда кәҗә эзеннән,
кинәт кәҗә бәтиенә
әверелгән үзе дә.

Диңгезләр — убылган таулар...
Диңгез күргәч, туңкаеп
ятып тозлы су эчкәндә
Аюдаг булган аю.

Без, кешеләр, — илаһилар!
Бездән көчле тик Вакыт...
Әллә без Ходай эзеннән
су эчтек микән ятып?

**Аюдаг**[1]

Помню сказку про братца Алёнушки,
как, испив из копытца воды,
превратился он тут же в козлёночка,
принеся себе уйму беды.

Море — схоже с горой опрокинутой,
раз медведь заплутал тут впотьмах —
пил у берега воду противную
и навек стал горой Аюдаг.

Я смотрю на себя и на ближнего —
наши души нельзя истребить.
Знать, когда-то из следа Всевышнего
довелось нам водицы испить...

* * *

Тәрәзәнең аръягында
Кыш дигән комсыз патша

---

[1] *Аюдаг* — Медведь-гора в Крыму возле Гурзуфа.

безнең якның яшеллеген
бетергән инде ашап...

Бирге якта өй гөленең
әле дөнья күрмәгән
ботаклары, яктыга дип,
хәтәр якка үрләгән.

Яшәп-яшәп гыйбрәт алган
ботаклар, киресенчә,
афәттән котылмак булып,
кояшсыз нурлар эчә...

* * *
За оконным стеклом — Царь Зимы.
Он жесток. Он объел все деревья.
Так и кажется: дай ему время —
попадём к нему в лапы и мы!

Ну, а в комнате нашей — цветок,
ему мнится, что там, за оконцем —
всё залито чарующим солнцем,
и он тянет к нему свой росток...

А собратья его, что давно
этот мир, как горшок, обживают,
те лишь головы в плечи вжимают
и глядеть не желают в окно.
Здесь — теплей им... И пусть тут темно —
жизнь важнее для них, чем кино.

**Миләш**

Һәр бөртеге тулы, шома,
йомры мәрҗәнгә тиңдәш.
Чәчәк белән ярышырлык
кырау тимәгән миләш.

Кызыгасың һәм өзәсең...
Тешлисең дә сытасың...
Ләкин килми матурлыкның
ямьсез тәмен йотасы.

Һәм беренче кырау төшә —
бөрешеп кала миләш.
Ә кыраулар тигән миләш
хәтта йөземгә көндәш.

**Рябина**

Пока она не тронута морозом,
она горит и светит, как коралл.
Рябина — конкурентка даже розам,
я б лишь её в букеты подбирал.

Сорву с ветвей горящие рубины
и брошу их на плоскость языка...
И тут же — наземь выплюну рябину,

что так невкусна, терпка и горька!

Когда ж, как тать, прокравшись по ложбинам,
мороз по рощам выпустит заряд,
ты не смотри, что сморщится рябина —
она теперь вкусней, чем виноград.

* * *
Керфекләр саклый күзләрне,
урманнар — елгаларны.
Сөрү җирләре артсын дип,
күпме кистек аларны?!

Урманнар урынын алды
кукуруз басулары...
Төрле бик файдалы агу
агулады суларны.

Туфрак акты елгаларга,
котырды суүсемнәр...
Балыкларга ялварыйк без:
үсемнәрне киссеннәр...

* * *
Как ресницы сторожат глаза —
так леса оберегают реки...
Сотни лет корчуем мы леса,
чтоб растить зерно для человека!

Там, где сосны с елями росли,
Кукурузы пущены коренья,
и в речные воды потекли
ста ручьями суперудобренья.

Зарастают нынче русла рек
водорослей массой грязно-чёрной.
Как ты с ними сладишь, человек?
Рыб проси, чтоб занялись корчёвкой!

* * *
Кояш кайчак якынлаша
кибән-кибән көртләргә.
Көртләр инде әзер кебек
ялкын булып дөртләргә.

Кулны җылытасы килә
карларның ялкынында...
Ләкин юлыгасың бары
табигать салкынына.

Күңелнең дә була шундый
үтә сәер чаклары —
кышкы кояш кебек матур,
тик салкын учаклары.

* * *
Зимою солнце ходит низко,

так, что аж чудится: снега,
к каким оно подходит близко,
сейчас вдруг вспыхнут, как стога!

И мы порою верим сами,
что там для нас костёр горит,
но сунешь руки в это пламя —
а в нём лишь холод изнутри.

Вот и с душой такое диво
бывает в жизни, и она —
как солнце зимнее, красива,
но пуще снега холодна...

* * *
Су буенда тал-тирәк,
күләгәсе су керә.
Тал-тирәк су-көзгедә,
ниһаять, үзен күрә.

Ул әнә нинди яшел!
Ул әнә нинди куе!
Болытларга тиярлек
булып үскән ич буе!

Ник бары күләгәсе?
Гәүдәсе дә теләде...
Көнчелек хакын тирәк
артык кыйммәт түләде...

* * *
Ивушка в воду смотрелась, как в зеркало,
речку моля, чтобы вид не коверкала.

И увидала своё отражение,
и от восторга пришла вся в движение.

Дёрнулась с мыса себе же навстречу
и... обвалилась в бегущую речку...

* * *
Эсселектән әлсерәгән
көн капланган елгага.
Тал ышыгына елышып,
куерган җилләр ага.

Ул да җылы — кояш нуры
суга тамып эрегән.
Тәнең дәрман ала алмас
бу суда су керүдән.

Җәй челләсе. Су күкләргә
күтәрә алсу рәшә.
Җан, үзе дә теләмәстән,
дөньяга күзне дәшә.

* * *

От жары аж вскипает река.
Солнце не угасает.
Ветер прячется в тень ивняка,
но и тень не спасает.

И струится он, как кипяток,
через рощицу сосен.
Что за прок окунаться в поток,
где расплавлено солнце?..

Лето катится в даль, не спеша,
под сияющей сенью.
И невольно мечтает душа
о прохладе осенней.

* * *
Җир җиләкләре җемелди
болыннар-тугайларда...
Чалгычылар керештеләр
чалгыларын кайрарга.

Күләгә кагылудан да
кузгала күбәләкләр,
әйтерсең лә куркып оча
аллы-гөлле чәчәкләр...

Болыннарда җиләк исе,
елгада балык исе...
Күңел сәрхушләнеп ала,
бутап эчкәч икесен...

* * *
Как много земляники! Туесками
носи её с зари и до зари!
По вечерам звенят во мгле брусками,
оттачивая косы, косари.

Лишь тень качни — и над густой травою
взовьётся пёстрых бабочек туман.
Синеет неба высь над головою.
Плывёт над лугом сладких трав дурман.

Пропахли рыбой быстрых речек воды.
Несётся запах ягоды с полян.
Душа ждала общения с природой —
и от неё, как от вина, я пьян...

* * *
Җылы якта сыерчыклар
чykканнар инде юлга.
Кар сулары, сут булыйк дип,
уйсу җирләргә тулган.

Урманнар гына кыш белән
хушлашырга ашыкмый!
Әллә андагы каеннар
ак карларга гашыйкмы —

китәргә ашкынган карның
басканнар чабуына.
Күрше имән ботагына
кара каргалар кунган...

* * *

Криком взрезая небес парусину,
птицы на родину правят разбег.
Талые воды текут по низинам,
точат собою слежавшийся снег.

Только леса не торопятся сбросить
грязный халат надоевшей зимы,
словно берёзы их жалобно просят:
«Не раздевайте! Простудимся мы».

И, собираясь ответить не грубо,
чтоб ненароком не вызвать их плач,
сев на макушку могучего дуба,
пробует голос вернувшийся грач...

**Кыргый алмагач**

Кайдан, ничек килеп чыктың?
Нигә монда төпләндең?
Шушыдыр, ахры, тормыштан
бәхет өмет иткәнең?

Син купшы да, син куе да —
барлык ботагың исән!..
Аларда тик балан зурлык
ачы алмалар үсә...

Күзәтәсең киңлекләрне,
син саф һава сулыйсың...
Сиңа карап, килә никтер
бүре булып улыйсым...

**Дикая яблоня**

Зачем ты здесь — за столько вёрст от сада,
где королевой ты могла цвести?
Ужель твоя мечта, твоя отрада —
одной расти?

По красоте ты, право, как конфетка,
и не подумай, что я слишком строг,
но разве ж это яблоки на ветках?
Это — горох!

Да, над тобой — не дом многоэтажный,
а чистый свет небес над головой.
Но как представлю, что я жил бы так же —
хоть волком вой...

**Беренче кар**

Кичә кара торган җирләр

калды бүген кар астында...
Туйган иде инде күзләр
кара күзләр карасыннан.

Кичә кургаш кебек күкләр
җирдән якты иде күпкә.
Бүген инде җир яктырак —
күк калган хәтта аптырап...

Без, кешеләр, шаккатмыйбыз —
без күнеккән утка-суга,
безне Җир дә, Күк тә талкый,
аяз көнне яшен суга...

**Первый снег**

Ноябрь задержался у крайней черты.
Устали глаза от сплошной черноты.
Но вот, наконец-то, на чёрный простор
декабрь белоснежный платок распростёр.

Сливались с землёю вчера небеса,
а утром — сияние режет глаза!
И небо растерянно смотрит в поля —
куда нынче чёрная делась земля?

Лишь мы к переменам привыкли давно,
и нам что вода, что беда — всё равно,
нас небу греть — мука, земле носить — лень,
и может нас гром поразить в ясный день...

* * *
Җилләр сулап яшәгәндә,
йөрәктә дулкын тора:
мәхәббәт булып иркәли,
нәфрәт булып котыра,

агымга каршы куалый
уйларны, хыялларны,
хәтта искә дә төшертми
куркыныч кыяларны...

Вакыт еллар фасылына
бүленми генә ага...
Күзгә дулкын арасыннан
кем күзе миңа бага?..

* * *
Если ветер ты впустишь в грудь —
он поднимет в душе цунами.
Не грусти. И готовым будь
ко всему, что случится с нами.

Аж до неба встаёт волна,
разметая строй дум усталых!
Не подскажет тебе она
о торчащих по курсу скалах.

Воет время, как океан,
и развёрстая пасть — всё ближе...
Чьи глаза сквозь седой туман
я, как в зеркале мутном, вижу?..

* * *
Иртәгә буран булыр күк —
кояш байый кызарып...
Биш-алты кар бөртеге дә
бездә эшне бозарлык.

Иксез-чиксез илебездә
кыш күбрәк хөкем сөрә.
Кырыслыкка күнеп булмый
хөкем сөргәнгә күрә —

катырганга күрә канны,
сындырганга шартлатып...
Аһ! Кояш кызарып байый —
без торабыз шаккатып...

* * *
Диск солнца садится в багровый туман.
Наверное, завтра начнётся буран.
Нам страшно. Не каждый ведь в жизни — герой.
Нас пара снежинок пугает порой.

Над нашей Отчизной — полгода зима.
Снега и морозы нас сводят с ума.
До мая метели бушуют во тьме.
Как можно привыкнуть к такой кутерьме?

Нас за нос кусает свирепый мороз!
Нас вьюги с разбега целуют взасос!
А мы — в центре белого вихря стоим,
за солнцем багровым с восторгом следим...

* * *
Өянкеләр, өянкеләр,
тамырыгыз судамы?
Мин Зөя ярында тудым —
Зөя суының дымы,

каным тамырлары буйлап
вакытны ташый-ташый,
күңелемнең болыннарын
сугара, җимли, ашлый...

Тамырым судан курыкмый —
мин бит нәкъ синең кебек:
ябалдашым күкне капшый,
тамырым — дәрья төбен...

* * *
С самой ранней поры своей — к ивам
я почтенье в душе берегу.
Я, наверно, родился счастливым,

жизнь прошла на речном берегу.

Вплоть до этой поры не иссякли
в моих венах стремнины её,
гонят времени быстрые капли
сквозь открытое сердце моё.

И стараюсь, как ивы те, весь я
так стоять и в труде, и в беде,
чтобы быть: головой — в поднебесье,
а корнями — поглубже в воде...

* * *
Көнне җайлы кичкән өчен, кояш
шатлыгыннан төсләр өләшә.
Алтын нурлар җыйган өянкедән
кичкә кергән елга көнләшә —

кояш нуры аңа калмый кебек,
китә кебек әллә кемнәргә...
Ә суының даһи көзгесендә
тапкырлана һәр төс меңнәргә.

Көзге үзен ни күз белән күрсен?!
Ничек күрсен елга үз төсен?!
Даһилыгын белмәгән даһидай
даһилана елга көзгесе.

* * *
Оттого, что день прошёл счастливо,
дарит солнце свет всем золотой.
Больше всех лучей набрала ива
и стоит, сияя красотой!

А река от ревности не может
свою злость на иву удержать.
(А сама — зеркальной гладью множит
всё, что только можно отражать.)

Нет прекрасней вот таких мгновений!
Я смотрю на мир, его любя.
Зеркало реки — оно, как гений,
что поёт, не слыша сам себя...

* * *
Урман күленә чумсам мин,
тапмамын кебек төбен
һәм Җирнең теге ягына
барып чыгармын кебек.

Юкса беләм: күлләр түгел,
хәтта диңгезләр төпле —
әкият яши хыялда
картаймыш көнгә тикле!

Алам көймә, керәм йөзеп
күлнең уртасына мин...

Ләкин чуммыйм — әкиятемнең
дөреслеген сынамыйм...

* * *
В лесное озеро лишь гляну —
и кажется: когда б пришлось
нырнуть в него — дна не достану
и Землю пронырну насквозь.

Но тут же ум даёт подсказку,
что даже моря — нет без дна.
Ну, а душа всё верит в сказку,
что тут — бездонна глубина...

Ответ — нетрудно обнаружить:
нырни — и он лежит на дне.
Но как же боязно разрушить
ту сказку, что живёт во мне!..

* * *
Тизрәк чум да чык яныма,
алтын чәчле кыз бала!
Гәүдәңдәге тамчыларны
күзләремнән кызганма!

Һәм күлнең рәхәтле дымын
кызганма кочагымнан —
сөлгедәй урап киптерим
йөрәгем учагында.

Юк! Куркытуым ихтимал...
Туйганчы йөз... Мин китәм,
күзләрем мондый бәхетне
күрмәсә дә бик күптән...

* * *
Ну, выходи же, выходи
ко мне на берег, златовласка!
Пусть капли по твоей груди
бегут, сверкая, — не щади
мои глаза! Пусть длится сказка.

Иди ко мне скорей, и пусть
осудит мир твою отвагу!
Я полотенцем обовьюсь,
чтоб отереть с тебя всю грусть,
как будто с плеч блестящих — влагу.

А впрочем — нет, я отойду
и нарушать твой мир не буду.
Резвись русалочкой в пруду,
я взгляд свой жадный отведу...
Хотя его — так тянет к чуду!

* * *
Көз — гомернең иң бай чоры,
барлык нәрсә анда бар:

язгы ташкын, җәйге гөлләр,
алтын алма, кышкы кар!

Көз кушымталы җыр кебек:
иң әүвәл уйландыра,
аннары йә суга сала,
йә утларда яндыра.

Көзләрне без юкка гына
сагышлы дибез, сүрән...
Көз шагыйрьләр күңеленә
бай шигырь булып керә.

* * *
Осень — копилка года, в ней, как в богатой сказке,
собрана вся погода, скоплены звуки, краски.
Звон ручейков весенних, ягоды, птицы, гнёзда.
Яблоки, копны сена, иней, снежинки, звёзды.

Осень — она, как песня: нет её без припева —
то она в поднебесье реет, не зная гнева,
то обожжёт вдруг стужей, ветром сырым остудит,
хрустнет ледком на луже... (Что ещё завтра будет!..)

Зря говорят, что осень — хмура, скучна, тосклива.
Тем, кто покоя просит — осенью жить счастливо.
Осень несёт поэту мудрость и вдохновенье,
и — он являет свету новое стихотворенье.

**Февраль**

Ыңгырашмыйм, сыкрамыйм да —
аңлый күрегез берүк, —
карым җыры менә шундый!
Ә җырлыйм күңел биреп.

Сагышларым үземнеке...
Үземнеке һәр көртем...
Мине башкача җырларга
өйрәтә алмый беркем.

Минем карым осталыкта
иң югары баскычта —
һәр кешене җырчы итә
көртләремә баскач та...

**Февраль**

Не стону и не ною
над писаньем стихов.
Просто там — за стеною —
нынче столько снегов!

Хлещет ширью безмерной
вьюги белая плеть.
По-другому, наверно,
мне уже не запеть.

Снег мне мука и счастье,
лишь сойду я с крыльца —
он меня в одночасье
превращает в певца.

* * *

Күңел җәйге елга кебек —
дулкынланмый, кымшанмый.
Шулай булып булуына
хәтта үзе ышанмый.

Ә югыйсә чоңгылларда
балыкны балык аулый,
һәм һавада керәшәләр
черки дәүләтен яулый...

Ә күңел җәйге елгадай —
һәм ваемсыз, һәм тыныч...
Керәшәләрне күрдем дә,
булып китте куркыныч...

* * *

Душа, как летняя река,
когда она без волн и ряби
течёт себе издалека
через леса, поля и хляби.

Над ней — покой и тишина,
стрекозы весело летают.
А под водой идёт война —
там щуки мелких рыб глотают!

Мир любит негу и жару.
Но я смотрю, как над рекою
пичуги ловят мошкару —
и нет в душе моей покоя...

* * *

Кайчакларда мин кар баскан,
утлары сүндерелгән
өй итеп тоям үземне...
Һәм куямын дерелдәп.

Тәрәзәмне бәс каплаган —
керми дөнья яктысы...
Әллә ничек булып китә —
хәтта яшәү ят төсле...

Һәм ишекне кемдер кага...
Җаным куя дерелдәп...
Бер җылы сүз ишетәм дә
мин яңадан тереләм...

* * *

Я — дом, в котором нет печи.
Стою в завьюженной ночи,
до окон снегом весь завален.

И нет тепла в покоях спален.

Плотнее краски и белил
мне иней стёкла залепил.
Сквозь них — и солнцу не пробиться!
Душа моя — словно темница.

Но вдруг — как будто стукнут в дверь
иль прокричат в окно: «Ты верь!» —
и в щель сквозь иней солнце брызнет...
И я почую жажду жизни.

* * *
Була ул, була кайвакыт
дөньядан туйган чаклар...
Нинди дә булса корабта
кайсы да булса якка

китеп барасы килә бер
бернәрсә уйламыйча,
күзне йомып, җанны ачып,
давыллар коча-коча...

Ашкынып чыккан буласың...
Ни диңгез юк, ни кораб...
Ә бәхетле мәшәкатьләр
тора күзеңә карап...

* * *
Бывает, свет вокруг не мил!
сел на корабль бы и уплыл
в какие-то края чужие,
где горы и леса большие.

Туда, где блещет океан,
туда, где воет ураган,
и смерч хватает, что попало,
и сквозь туман чернеют скалы...

Очнусь и выбегу во двор —
там солнце льётся на простор.
Надёжен мир. Не рвутся снасти...
И в сердце вновь — покой и счастье.

**Уяну**

Җир шары эчендә кемнәрдер
ут яга еракта-еракта —
җылына башлады җир өсте,
су төште кар тулы ермакка.

Талларның очлары кызарды,
сут алды каеннар кайрысын.
Егетнең дә килде, ниһаять,
бер кызга сүз катып карыйсы.

Ә төнгә кергәндә, кар өсте
мең төрле төсләргә буянды...

Табигать һәрвакыт акыллы,
ә хәзер хисе дә уянды.

**Пробуждение**

Кажется, будто в глубинах Земли
черти горячий костёр развели,
раскочегарили страшный пожар —
аж от полей поднимается пар!

Чуя тот жар, краснотал покраснел,
пот побежал из берёзовых тел.
Парень подружку из дома зовёт...
(Сердце от жара взорвётся вот-вот!)

Так — до заката. И только в ночи
пламя стихает в подземной печи.
Но и ночами природа не спит —
жар тот глубинный ей душу томит.

**Туган җирем**

Һәрбер чишмәң синең көй чыгара,
һәр инешең җырга әйләнгән.
Үләндәге һәрбер чык тамчысы
әверелә нурлы сәйләнгә.

Һәр сукмагың синең — шигырь юлы,
зур күмәк хор һәрбер урманың —
гомер буе күрәм мин аларның
мәдхияләр җырлап торганын.

Алар — сиңа, сиңа, туган җирем!
Лаеклыга тиеш лаеклы!
Ничек кенә гасырлар юлында
саклап калыйк мондый байлыкны?!

**Родной край**

Каждый твой родник слагает песню,
каждая река звучит кантатой.
Раскатились росы в редколесье,
блещут в травах, точно жемчуг скатный.

Каждая тропинка — стих звучащий.
Словно хор объединённый, оду
в честь тебя поют лесные чащи,
поле, роща, сад — и вся природа!

Край родной! Моей души истоки!
Без тебя мне ни к чему награды.
Лишь скажи, как во всемирной склоке
мне не дать твои разграбить клады?..

* * *

Күренерлек болыт та юк,
ә һава никтер соры.
Кошлар үлеп сайрар вакыт,
ә кая тургай җыры?!

Җил искәне дә сизелми,
суда юк сыңар шадра.
Керәшәләр дә күренми
кәрәздәй сары ярда.

Вакыт та тукталган кебек,
аптырап әллә нидән...
Торгынлык барлык нәрсәгә
сихере белән тигән...

* * *
И туч как будто в небе нет,
а день — не весел.
Куда-то делся солнца свет,
нет птичьих песен.

Застыла речка под горой,
спит лес дремуче.
И ласточек не вьётся рой
у жёлтой кручи.

Спит время, свившись калачом,
про всё — забыло...
Как будто вдруг параличом
весь мир разбило.

* * *
Тын суларның тынычлыгын
алыр өчен таш җитә...
Җанны дулкынлатыр өчен
бер сикергән каш җитә...

Кайнар комнан да кайнаррак
гашыйк кочак кызуы...
Суда — дулкын, җанда — ялкын
яшь гомернең узуы...

Тын суларның көзгесендә
чагыладыр бар җиһан...
Чалкан ятып күккә бакса,
күзендә мин чагылам...

* * *
Чтоб гладь речную всколыхнуть —
в неё лишь камень бросить надо.
Чтоб загорелась чувством грудь —
довольно слова или взгляда.

Песок у берега горяч,
но горячей — любимой руки.
Уходит молодость — не плачь,
ей наплевать на наши муки.

Блестит, как зеркало, вода,
а в ней — Вселенная двоится.
Так наши взгляды иногда

любимых отражают лица...

* * *
Каен кайрысына кайнар
шигырь язасым килә —
җаным язларны өзелеп
көткәнен аңа сөйләп.

Кар астында умырзая
бөреләнә шикелле...
Ә бит вакыт кышка бара —
сау калуы икеле.

Тик шигырь яза алмадым —
каләмдә кара туңды...
Ләкин ут булды җанымның
язларны яратуы.

* * *
О том, как хочется весны —
пишу стихи я на берёзе.
А роща спит и видит сны,
скрипя стволами на морозе.

Смотрю на выросший сугроб
и жду подснежников до боли.
Но до весны ещё и троп
лучи не вычертили в поле!

Лежит, как шапки, снег на пнях.
Мой стих даёт сплошные сбои.
Это тоска о майских днях
всю душу выжгла мне собою...

* * *
...Ә өянке суга кереп бара,
кар өстенә яфрак сибәләп...
Җәйнең эссесеннән кача идек
ышыгына аның килгәләп.

Ботаклары суга тигән иде —
балык тота диеп уйларсың.
Йөзеп килеп аңа каба иде
ап-ак казлар койган кавырсын.

Хәзер инде бөтен елга ап-ак.
Боз астында аның агышы...
Ә өянке ярдан суга атлый,
ишеткәнгә җәйләр тавышын...

* * *
Ветла бредёт среди холодных вод,
роняя листья на прибрежный лёд.
А не вчера ли был июльский день,
и мы под ней себе искали тень?

Свисала в волны сеть густой листвы,

как будто мелкий невод для плотвы,
но не ловилась рыба в эту сеть,
а только сор да белый пух гусей.

И вот река — белей день ото дня,
по берегам исчезли зеленя,
ветла глядит на воду и молчит,
а из-под льда ей летний день журчит...

* * *
Су ул — Җир шарының мие!
Суда галәми хәтер!
Сөйләшә белеп сөйләшсәң,
яралмыш серен әйтер:

җанның барлыкка килүен
һәм хәрәкәтен аңның,
Җир шары йөзен үзгәрткән
бөек афәтләр санын...

Каргарга ярамый суны,
ярамый рәнҗетергә —
һәр сулу саен ул дару
йә агу булып керә...

* * *
Вода — это мозг планеты,
в ней вызрели жизнь и речь.
В воде — есть на всё ответы,
и надо лишь их извлечь.

Надёжней, чем в картотеке,
лежат в ней который год
и знанья о человеке,
и эволюции ход.

Не плюй никогда в криницу,
пусть чистой бежит струя,
поскольку — к тебе возвратится
и яд твой, и злоба твоя...

* * *
Гаиләсенә җиһанның
ник китердең ят кеше?

**Г.Тукай**

Тукай бакчасында кар сибәли,
вак һәм җылы — яңа он сыман...
Тегермәнче кебек, телгә салып
эвәләргә хәтта ымсынам.

Ә кар эри керфегемә тиеп —
төшкән чагында ук чыланган...
Әллә ул да, нәни Тукай кебек,
ят булганмы чиксез җиһанга?..

Тукай бакчасында кар сибәли...
Ак япмада тора бар агач...
Әллә нишли күңел, керфектәге
тамчы аша күккә карагач...

* * *

Скажи, зачем в семью Вселенной
ты чужаком меня ввела?..

**Г.Тукай**

В саду Тукая — снежная пороша
так невесома, сказочна, легка.
Земля — на двор на мельничный похожа,
в котором всё усыпала мука.

Снежинки тают прямо на ресницах
(знать, родились с горячею душой).
Снег над землёй так радостно кружится,
он, как Тукай, для Космоса — чужой.

Здесь мной давно исхожены тропинки.
Но как же сильно изменился сад,
если на мир смотреть через снежинки,
что, словно слёзы, на глазах висят...

* * *

Кичә генә кара-көрән җирләр
көмеш парча юрган ябынды,
ә парчаның барлык җепләрендә
миллион сәйлән лампа кабынды.

Җан җылысын югалтмаган елга
ак ярларга карый аптырап —
алар көмеш төсле чабаклардан,
судаклардан күпкә яктырак!

Ялтыравык һәрнәрсәгә гашыйк
саесканны гына карагыз —
көмеш Җирне урламакчы тизрәк!
Көче җитми — тора чарасыз...

* * *

Те поля, что чернели вчера ещё замертво,
нынче белой парчой нарядила зима.
Я смотрю на разлитое снежное зарево
и себе говорю: «Не сойти бы с ума!»

Позабыла река настроенье игристое
и не может найти в изумленье слова,
чтоб признать, что её берега — серебристее,
чем живущие в ней судаки и плотва.

А сорока, какую и плёткой свистящею
не отучишь хватать то, что ярко блестит,
утащила б в гнездо всю планету блестящую —
да не знает, как в клюве её унести...

* * *

Ак кар дип башлап, шигырьне
ал кар дип дәвам итәм.
Күзне ачыбрак карасам,
ал карым зәңгәр икән.

Зәңгәр — иң яраткан төсем,
зәңгәргәдер күзләрем.
Күз алдында зәңгәр карым
шәмәхәгә үзгәрде.

Офык артларына чумды
рәссам кояш — югалды...
Карым, шатлыктан арыган
күңелдәй, төссез калды.

* * *

«Снег лежит на полях бел, как мел», —
я сказал и вокруг поглядел —
там алели снега, словно знамя,
а потом посинели внезапно.

«Снег синее, чем глади озёр», —
сказал я и взглянул на простор.
Но картина меня огорчила —
снег уже был похож на чернила.

А лишь солнце ушло на покой —
сумрак смазал все краски рукой,
и ни цвета, ни света не стало,
как в душе, что безмерно устала...

* * *

Оялчан инешләр була —
агалар яшеренеп,
ярларында шаулап үскән
таллыкларга төренеп.

Сулары бик сай булудан
инешләр ояладыр...
Бәлки, алар яшерәдер
сандугач ояларын!

Таңда алар тынып тыңлый
сандугач чут-чутларын...
Оялчан инеш асылда, —
сандугач сөйгән яры.

* * *

Есть речки, что стеснительны, как люди,
они текут, забившись в камыши,
словно боясь, что кто-то наглый будет
лезть в тайны их чувствительной души.

Они бегут вдоль рощи и болота,
стыдясь своей ничтожной мелкоты.

(А может, просто не хотят, чтоб кто-то
пугал их птиц и мял ногой цветы...)

С лесной опушки им поют кукушки.
Для них слагают оды соловьи.
Текут стыдливо мелкие речушки...
Мои родные... Милые мои!..

* * *
Яфрак шавын тыңлап сокланамын —
тормыш җыры өмет кабыза...
Ә бу таллар яшел яфракларын
дулкыннарга сибеп агызган.

Таллар белән, алар шәрә калгач,
сөйләшергә тели күңелем.
Моңлы чакта алар юмарт бирә
гасырлардан килгән гыйлемне.

Тиздән елга бозга камалачак,
тал суты да туктап калачак...
Икесе дә, тормыш җыры итеп,
язлар шавын каршы алачак.

* * *
Мне шум листвы — как песен переливы,
что славу жизни воздают везде!
Но больше всех чаруют душу ивы,
что моют косы тонкие в воде.

Из года в год, как будто к старшим сёстрам,
я приезжаю к ним издалека.
Лишь подойду — и грудь уколет остро
за их судьбу неясная тоска.

Они стоят, согнувшись сиротливо,
в преддверье снега, холода и сна —
и тихо плачут... Не сдавайтесь, ивы!
Ещё придёт к вам с песнями весна!

* * *
Су төбендә алтын кәрәкәләр
кереп чумган җылы дуенга.
Күл өстендә йөзгән яфраклар да
яр читенә килеп сыенган.

Күл өстеннән төнлә исеп үтте
көзге җилнең шадра хәбәре.
Җәе буе ләззәт эчкән дөнья
уйлап куйды шунда хәтәрне.

Бөтен нәрсә әзерләнә кебек
адым атларга дип чик аша...
Һәм күңел дә Җирнең әйләнеше
тизлегенә ныграк тоташа...

* * *

Дождь осенний воду остудил.
Караси зарылись в тёплый ил.
Жёлтых листьев яркий хоровод
потускнел на фоне серых вод.

Подняв брызги, точно капли слёз,
ветер весть над озером пронёс,
что минуло время для услад
и в природе зреет снегопад.

Смолкло всё — и лес, и стаи птиц,
подойдя к важнейшей из границ.
И душе понятна стала вдруг
связь с тем миром, что стоит вокруг...

**Әбиләр чуагы**

Шул чаклы көмеш пәрәвез!..
Кайдан килә икән ул?
Әллә аны бушлай гына
җибәрәме бүтән ил —

бездән бераз хәллерәге,
юмартлыкта узганы?
Ни булса да, хәерлегә
булсын безне кызгану...

Без дә бай! Без күнекмәгән
бүләк алырга бушка —
әзерлибез җибәрергә
башка илләргә кошлар!..

**Бабье лето**

Сколько нитей серебряных вьётся!
И откуда их столько берётся?
Видно, это подарок богатый
из страны, где богатства лопатой
разгребают и дарят соседям —
словно корм в зоопарке медведям...

Ничего! Мы и сами не нищи!
И у нас есть в загашнике тыщи.
Тыщи птиц перелётных в озёрах —
мы отправим их к вам очень скоро.

* * *

Күл буенда — учак эзе.
Кемнәр яндырды икән —
бәлки, төркемдер, ә бәлки
пар каен кебек икәү?

Учакның уты чәй генә
кайнатып калды микән?
Әллә бөтен кайнарлыгын
кочакка салды микән?

Әллә очкыннар сүндеме,

суга төшеп кочактан?
Күпме генә тырышсам да,
сер чыкмады учактан...

* * *
На озёрном берегу — след костра,
как печать средь травинок зелёных.
Может, были тут туристы вчера,
а, быть может, лишь пара влюблённых.

Может быть, только чай тут кипел.
А, быть может, огонь от поленьев —
долетел до сердец их и тел,
тронув жаром ладони, колени...

Ну, а может, он быстро погас,
задохнувшись в холодном тумане,
и оставил загадкой для нас
чёрный след на зелёной поляне...

* * *
Җәйләрнең дә шундый чагы була —
суларына чыга каз тәне.
Таллар, камышларны бизгәк суга,
әйтерсең лә алар хасталы.

Вертолёттай энә караклары,
күбәләкләр әле ангарда —
моторында майлары суынган.
Кояш нуры көтә алар да.

Менә җайлап кояш күтәрелә,
су шомара нурлар назыннан...
Кичәге җәй кабат безне били,
сискәндереп алгач аз гына.

* * *
...И среди лета вдруг бывает день,
когда вода пойдёт «гусиной кожей»,
а камыши забьются в мелкой дрожи,
и всё собой накроет сверху тень.

Ни стрекозы не взмоет вертолёт,
ни из ангара бабочка не выйдет —
в холодной мгле её радар не видит,
в моторе масло стынет, словно лёд.

Им так нужна энергия небес,
где летний жар разлит по небосводу!..
...И снова солнце — всходит им в угоду,
и плещет рыба, и смеётся лес.

**Гладиолуслар**

Кызганмагыз өзелгән дип,
уфтанмагыз сула дип —
без дөньяда яшәп калдык
шаулатып һәм дулатып.

Кешеләрнең бәйрәменә
төсебезне өстәдек —
бизәп тордык нурлы туйлар,
туган көннәр өстәлен...

Матурлыкмы коткаручан?
Кем әйтә шулай диеп? —
Матур чәчәкләр иртәрәк
үлә, пычакка тиеп...

**Гладиолусы**

Не жалейте, что срезали нас.
Мы засохнем — но это неважно.
Важно то, что последний свой час
мы встречаем легко и отважно.

Эта наша отвага — не жест,
что внутри себя зол и отчаян.
Мы росли на земле — для торжеств,
чтоб никто не ходил опечален.

Мы б хотели, чтоб вид красоты
мог и вправду спасти всю планету.
Но — увы! — чем прекрасней цветы,
тем быстрей их сорвут для букета.

* * *

Салкын иртә...
Салкын су...
Йөрәгем дә
ялкынсыз...

Бикле күңел
ишегем —
утырамын
күшегеп.

Сайрады кош...
Җил өрде...
Җанда ялкын
терелде...

* * *

Дождик над садом
день ото дня.
В сердце — досада,
нет ни огня.

Запер я душу
мощным замком.
Как бы мне стужу
выгнать пинком?

Крошек для птиц я
сыплю в ладонь...
Верю — родится

в сердце огонь!

* * *
Хисләргә бай булсалар да,
көзләр күңелне баса...
Бәлки, рух сытылыр иде,
алтын көзләр булмаса.

Әбиләр чуагы килеп
өсти көзгә җылысын —
бер мизгеллек наз хакына
алданасың, чыдыйсың...

Офык өстендә болытлар
куерган саен, көзнең
салкын акылдай алтыны
бераз юата безне...

* * *
Хоть и богата осень чувствами,
но угнетает душу холодом.
Дух ослабел бы, как от голода,
не поддержи его искусствами!

И бабье лето за туманами
идёт, чтоб взор слепить нам красками.
И мы себя, как в детстве сказками,
опять даём ему обманывать.

Ну, а потом над горизонтами
сойдутся туч полки угрюмые,
чтоб, глядя в небо, мы подумали,
что мир красив не только золотом...

* * *
Яңгырлы кичләр һәм
томанлы иртәләр
уйларны зыкылы
юлларга кертәләр...

Дөньяның кояшын,
табынның ашлысын,
кочакның кайнарын
сагына башлыйсың...

Җил-давыл тетрәтә
күңелең кыясын...
Һәм томан тарала...
Һәм калка кояшың...

* * *
Вечера дождливые,
дни насквозь туманные —
дарят нам тоскливые
образы обманные.

Как слюною сочною,

грудь тоскою полнится
по объятьям солнечным,
по горячим полночам...

И влетает молния
в сердце вспышкой яркою.
И в душе намоленной —
всходит солнце жаркое!

**Суюров Фарит Абдрахманович**
**Харисов Ренат Магсумович**

Пейзаж. Лирика
Альбом

Казань. Татарское книжное издательство. 2008
На татарском и русском языках

**Суюров Фәрит Абдрахман улы**
**Харисов Ренат Мәгъсүм улы**

Пейзаж. Лирика
Альбом

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Р.Х.Хәсәншин*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Н.И.Максимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 29.07.2008. Форматы 90г60 1/8.
Шартлы басма табагы 13,5 + фор. 0,5. Шартлы буяу-оттиск 55,5.
Нәшер-хисап табагы 8,1 + фор. 0,88. Тиражы 1000 д. Заказ Т-770.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.